ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2017 елның 24 марты**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 645**

Зеленодольск шәһәре территориясен санитар чистарту һәм төзекләндерү буенча гомумшәһәр чараларын үткәрү турында

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен санитар чистарту һәм аны санитар-эпидемиологик һәм экологик иминлеккә туры килә торган хәлгә китерү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2017 елның 1 апреленнән 2017 елның 31 маена кадәр Зеленодольск шәһәре территориясен санитар чистарту һәм төзекләндерү буенча ике айлык игълан итәргә (алга таба - ике айлык).

2. Шәһәр территориясен санитар чистарту буенча чәршәмбе өмәләрен 05.04.2017, 12.04.2017, 19.04.2017, 26.04.2017, 03.05.2017, 10.05.2017, 17.05.2017, 24.05.2017, 31.05.2017 көннәрендә үткәрергә.

Идарәче компанияләргә, торак милекчеләре ширкәтләренә, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренә йорт яны территорияләрен җыештыру буенча халык катнашында шимбә өмәләрен 01.04.2017, 08.04.2017, 15.04.2017, 22.04.2017, 29.04.2017, 06.05.2017, 13.05.2017, 20.05.2017, 27.05.2017 көннәрендә оештырырга.

3. Предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләренә, оештыру хокукый формаларына һәм милек формаларына карамастан, бакчачылык җәмгыятьләре һәм гараж кооперативлары рәисләренә санитар чистарту һәм санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү буенча түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- кушымтада күрсәтелгән, бүленгән территорияләр картасына ярашлы рәвештә, шәһәр территорияләре участокларында санитар чистарту һәм санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү буенча чәршәмбе өмәләрен үткәрүне оештырырга;

- ике айлыкны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы затларны үз боерыклары (күрсәтмәләре) белән билгеләргә. Боерыкларның (күрсәтмәләрнең) күчермәләрен «ТР ЗМР торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУда 4-64-

43 факсы яисә blag3@mail.ru электрон почтасына 2017 елның 30 мартына кадәр тапшырырга.

Чәршәмбе, шимбә өмәләрендә җәлеп ителгән кешеләр саны, техника турындагы мәгълүматны атна саен 4-62-33 телефоны аша яисә blag3@mail.ru электрон почтасына хәбәр итәргә.

4. «ТР ЗМР торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты» МБУ ике айлыкны үткәрү буенча эшләрне координацияләүне һәм оператив мәгълүмат җыюны тәэмин итәргә.

5. «Зеленодольск шәһәренең коммуналь хуҗалыгы» МУП өмәләр үткәрү урыннарында җыелган чүп-чарны үзәкләштерелгән чыгаруны оештыруны тәкъдим итәргә.

"Экоресурс" МУП каты көнкүреш калдыклары полигонына чүп-чар кабул итүне тәэмин итәргә.

6. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче
А.Х.Сәхибуллин